Мәкалә З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» («Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә») исемле беренче татар детектив романының режиссер Р. Әюповның сәхнә интерпретациясе үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган. Бу әсәрнең татар әдәбиятында өйрәнелү тарихы системага салынган. Мәкаләдә инсценировкадагы персонажлар системасы, образларның идея-сәнгати потенциалы ачыкланган. Прозаның сәхнә интерпретациясендә көнчыгыш һәм көнбатыш традицияләренең үзенчәлекле синтезы күрсәтелгән. Р. Әюповның үз спектаклендә әдәбият, кино, бию, музыка, цирк кебек төрле сәнгать төрләренә мөрәҗәгать итүе исбатлана.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, татар театры, детектив, Заһир Бигиев, Ренат Аюпов

## Кереш

Әдәбиятта детективтан да популяррак жанрны күз алдына китерү мөмкин түгел. Криминаль эчтәлекле әсәрләрне элек тә, бүген дә олысы һәм кечесе йотлыгып укый. Татар әдәбиятында да детектив жанрның тарихы шактый бай. Әлеге жанрдагы беренче әсәр 136 ел элек иҗат ителгән. «Татар прозасында детектив әдәбият әсәрләре XIX йөз ахырында языла башлый. Татар әдәбиятында детектив юнәлешнең барлыкка килүе, бер яктан, шәһәр халкы һәм җинаятьләр саны арту, икенче яктан, рус һәм чит ил әдәбиятларының тәэсире көчәю белән бәйле» дип саный Р.Ә. Мостафин [1].

Әдәбият белгече Р. Галиуллин фикеренчә, Заһир Бигиев татар әдәбиятына мондый жанрның кирәклеген аңлаган беренче татар язучысы була. Татар әдәбиятында реалистик роман жанрына һәм публицистикага нигез салучы Заһир Ярулла улы Бигиев 1870 елда Дондагы Ростов шәһәрендә ахун гаиләсендә туа. Булачак әдип башлангыч белемне рус гимназиясендә ала, рус телен һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәнә, французча да белә. Шул ук елларда Заһир матур әдәбият белән дә кызыксына башлый. Атасы үлгәч, анасы Фатыйма аны, рус мәктәбеннән алып, мәдрәсәгә бирә. 1886–1891 елларда Заһир Бигиев Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый. Биредә дин сабаклары белән бергә, гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә, матур әдәбият белән кызыксынуын дәвам итә, рус һәм француз язучыларының әсәрләрен яратып укый. 1891 елда мәдрәсәне тәмамлагач, З. Бигиев туган шәһәренә кайта һәм гомеренең ахырына кадәр анда мулла булып тора. Бер үк вакытта ул дөньяви белемен күтәрә, әдәбифәнни китаплар укый. 1893 елда З. Бигиев, Урта Азия халыкларының тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен өйрәнү максаты белән, Төркестан буйлап сәяхәт кыла. З. Бигиев берничә тапкыр Санкт- Петербургта, Мәскәүдә, Кырымда була. Ул рус, төрек, Көнбатыш Европа әдәбиятларын тирән белгән, берничә чит телдә сөйләшкән. Уналты яшендә З. Бигиев үзенең беренче әсәрен – «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» исемле романын яза. Детектив жанрда язылган бу роман 1887 елда Казанда басылып чыга (Бу турыда тулырак: [2, с. 10–11]). Әдәбият белгече С.Х. Хафизов, беренчеләрдән булып, татар телендә язылган әлеге детективның француз Э. Шаветтаның “Миллионнарга ау” дигән романы [3, с. 113] белән аваздаш икәнлеген әйтә, анда да жуликлар Анджелла исемле чибәр кызның бирнәсе өчен тозак коралар [4].

Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театры 87 нче театр сезонын Заһир Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз

Хәдичә» әсәре нигезендә куелган спектакль белән ачты.

## Тикшеренү өчен материаллар һәм методлар

Анализ өчен материал буларак, З. Бигиевнең "Өлүф яки Гүзәл кыз Хәдичә" романы буенча Р. Әюпов эшләгән "Гүзәл кыз Хәдичә" инсценировкасы алынды [14]. Тикшеренү предметы – күрсәтелгән романның татар сәхнәсе өчен сәхнәләштерелгән инсценировкасының стиль үзенчәлекләре. Безнең тикшеренүнең теоретик нигезен Л.Ф. Шкилеваның [5], С.Н. Скороходның [6], Д.Р. Фәрдиеваның [7] хезмәтләре тәшкил итә.

З. Бигиевнең иҗаты татар әдәбияты белгечләре М.Х. Гайнуллин [8, 208–229 б.], Ф. Мусин [9, 302–318 б.], Р.З. Даутов [10, 360–379 б.], Х.Й. Миңнегулов [11, 97–103 б.], Ф. Бәширов [12, 392–400 б.], А. Ахунов [13, 30–33 б.] һ.б. тарафыннан өйрәнелгән. Безнең тикшеренүнең яңалыгы З. Бигиевнең "Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә" романының сәхнә инсценировкасындагы сәхнәләштерү үзенчәлекләрен өйрәнүдән гыйбарәт.

З. Бигиевнең "Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә" әсәренең татар мәдәниятендә тоткан урынын өйрәнү барышында, мәдәни-тарихи ысул файдаланылды, ә әдәби чыганакны сәхнә әсәре итеп үзгәртү юлларын шәрехләү өчен, структур-функциональ методка мөрәҗәгать ителде.

## Фикер алышу

2 күренешле детектив романның аннотациясендә Р. Әюпов үзенең сәхнә әсәренең эчтәлеген болай дип тасвирлый: «Кунакханәдә яшь сылу кыз Зөләйханың үле гәүдәсе табыла, тикшерү башлана. Шик Казанның яшь бае Муса Салиховка төшә. Муса Петербург университетын тәмамлый, әмма әтисенең вафатыннан соң гаилә эшен дәвам итәргә, эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә мәҗбүр. Петербургта укыган чорда, ул әтисе белән Кырымнан килгән чибәр һәм укымышлы кыз Зөләйха белән очраша. Яшьләр бер-берсен ошата, алар арасында чын мәхәббәт уты кабына. Ләкин Мусаның өйләнешү тәкъдимен, егетне начар беләм дигән сәбәп белән, Зөләйханың әтисе кире кага. Бу вакыйгалардан соң бер ел уза. Сөйгәнен сагынуга түзә алмаган Зөләйха, әнисенә әйтеп тормыйча, Мусаны эзләп, Казанга килә. Әмма бу минутка Мусаның ниятләре инде үзгәргән була. Казанның иң бай кешеләреннән берсе, кызы Хәдичәгә бирнә итеп, йөз мең көмеш бирә. Кыз ярәшелгән, бер атнадан Мусаның никахы. Кунакханәдә очрашу вакытында ул бу турыда Зөләйхага әйтә һәм кызга, әнисе янына Кырымга кайтыр өчен, акча тәкъдим итә. Дөнья ямен югалткан Зөләйха чарасызлыктан тормышын үз-үзенә кул салу белән тәмамлый. Мусаны алда зур сынаулар көтә. Чөнки Хәдичәнең бирнәсе аның дусты Габденнасыйрны да җәлеп итә. Үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, ул Зөләйханың үлем алдыннан язган хатын яшерә һәм тикшерү эшләрен ялган юлга кертеп җибәрә. Шулай итеп, Муса төрмәгә эләгә. Ләкин, нәтиҗәдә, дөреслек таш ярып чыга – Зөләйханың үлем алдыннан әнисенә язган хаты табылып, Муса иреккә чыгарыла, алар Хәдичә белән өйләнешә. Җиңелгән Габденнасыйр атылып үлә» [15].

Р. Галиуллин әйткәнчә, З. Бигиев романында җинаять мотивы булып, Хәдичәнең йөз меңлек бирнә акчасы тора. Сюжет гадәти сораулар тирәсендә корыла: Кем? Ничек? Нәрсә өчен? Җинаять эшен тикшерү башлана. Романда авторның үзе сурәтләгән вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен һәрвакытта да төгәл ачыклап бетереп булмый. Муса да (Илмир Кашапов), Габденнасыйр да (Илдар Халиков) социаль чыгышлары ягыннан үзара охшаш, икесе дә бай ата-ана варисы һәм икесе дә бирнә акчасына кызыгып, Хәдичәгә өйләнергә тели. Шулай да автор Мусага күбрәк теләктәш, чөнки Әхмәди бай (Ринат Бәдретдинов) кызын аңа, Габденнасыйрга караганда, алданрак ярәшкән. Габденнасыйрның, мәкерле максатына ирешү өчен, Хәдичәнең әтисен алдап, Мусадан баш тартырга өндәвен З. Бигиев намуссыз гамәл дип бәяли һәм шуның өчен аңа "җәзасын" да бирә. М. Гайнуллин исә автор позициясен түбәндәгечә билгели: Муса, Зөләйхага биргән вәгъдәсен бозып һәм аны авыр вакытта ташлап, җинаять кыла. Биредә романның мәгърифәтчелек юнәлешен дә исәпкә алмыйча булмый: автор европалашу ягында, аның идеалы мәгърифәтчелектә. Романда ике төрле конфликт чагыла: җинаятьче белән аның корбаны арасында һәм җинаятьче белән шымчы арасында. Зөләйханың үз-үзенә кул салуы билгеле булгач, корбан белән җинаятьче турындагы беренчел күзаллаулар үзгәреш кичерә: кеше үтерүдә гаепләнгән Муса үзе корбанга, Габденнасыйр җинаятьчегә әйләнә. Тикшерүче-шымчы белән җинаятьче арасындагы конфликт нәкъ менә шушы серне ачыклауны күздә тота. Мусаны 10 еллык

сөргенгә хөкем итү “ялган” кульминация эффектын бирә. Чишелеш укучы өчен көтелмәгәнчә килеп чыга. Тышкы сюжет сызыгын шымчы Шубин “алып бара”, эчке сюжет җепләре Габденнасыйр кулында. Романга динамизм хас, автор хикәяләүне объектив алып барырга тырыша, моңа ретроспективалы өстәмә текстлар да ярдәм итә.

Шушы һәм башка сыйфатлар әсәрне традицион детектив буларак билгеләү мөмкинлеген бирә. Корбан, җинаятьче һәм шымчы типажлары зур төгәллек белән сурәтләнгән. Автор җинаять билгеләренә, дәлилләргә зур игътибар бирә, шымчының “ялган эз” буларак, дөреслеккә туры килмәгән нәтиҗәләре шулай ук әсәрне укырга кызыклы итә. Детектив тарихның сере интуитив рәвештә сәнгати юл белән ачыла» [2, 10–11 б.].

Н.С. Скороход раслаганча, «хәзерге заман театрында берничә сәнгать төренең синтезы беренче планга режиссёрның күзаллавын чыгара, спектакльдә катнашкан сәнгать төрләре аның иҗади концепциясенә буйсындырыла. Сәнгать төрләренең синтезы процессында театр сәхнәсендә әйдәп баручы роль прозага бирелә. Сәхнәдә романның художестволы аналогын булдыру ихтыяҗы театрдан сәнгатьнең башка өлкәләрендә тагын да көчлерәк тәэсир итү чаралары эзләүне таләп итә. Прозаның күләмле структурасын, аның байлыгын, идеяләрен һәм образларын тулы канлы итеп сәхнәдә иҗат итү өчен, театрга башка сәнгать төрләре белән актив рәвештә хезмәттәшлек итү таләп ителә. Проза сәхнәдә синтез процессларына этәргеч бирә һәм активлаштыра» [6, 54 б.].

З. Бигиев әсәре татар сәхнәсендә беренче тапкыр куелды. Р. Әюпов үзенең спектаклендә сәнгать төрләре синтезына мөрәҗәгать итә: әдәбият, кино, бию, музыка, цирк. Театр спектакле «ачык сәнгать структурасы» булып китә (Р. Барт) [16, 280 б.]. Режиссёр-сценарист проза белән эшләп, сәнгать төрләренең семиозисына ирешеп, театр поэтикасына төзәтмәләр кертә. Нәтиҗәдә актерларның пластикасы, кичерешләре, актерларның тамашачы белән аралашуы, музыканың функциясе, җиһазлар, сәхнә хронотобының семиотикасы үзгәрә. Режиссёр суд сәхнәсен кыскарта, финалга төзәтмәләр кертә: автор концепциясенә каршы килеп, ул Габденнасыйрны үтерми. Журналист Р. Латыйпов фикеренчә, сюжеттагы мондый чишелеш тормыш-чынбарлыкка туры килә [17]. Моннан тыш Р. Әюпов инсценировкасында автор салган эздән чыкмый.

Спектакль тамашачыларны XIX гасырга алып кайта. Казан урамнарының гөрелтесеннән тамашачы геройлар белән бергә сәүдәгәр Габдуллин (Хафиз Хамматуллин) кунакханәсе номерларына кереп ял итә. Тынычлыкны яшь хатынның үлеме турындагы хәбәр боза. Сәхнә күренешләре безне әле адвокат Андреев (Илназ Хисмәтуллин) өенә, әле Әхмәди бай (Ринат Бәдретдинов) өенә яки Нигъмәтулла (Фоат Зарипов) өенә алып китә. Муса (Илмир Кашапов) хатирәләренең хронотобы аның Петербургтагы тормышының картиналарын да үз эченә ала. Тикшерүче Шубин (Нурлан Шәехов) артыннан тамашачы әле полиция участогына, әле үз-үзенә кул салган кыз артыннан Кырымга барып чыга.

Сәхнә бизәлеше аскетларча гади. Анда театральлек рухы хөкем сөрә. Пространство сәке-күперләр хисабына оештырыла: алар әле караватка, әле бричка - җиңел арбага, әле вагонга, әле Сабантуй мәйданына әйләнә. Геройларның әлеге сәке-күперчекләр ярдәмендә пространство буйлап күчеше аларның әхлакый үсеше яки түбән тәгәрәвенә дә ишарә итә. Режиссёр кием алыштыру алымын да оста файдалана (Мәсәлән, Шубинның хәерче булып киенүе).

Мәгънәви яктан көчәйтер өчен, режиссёр газета таратучы малайларның һәм асрау кызларның хорына мөрәҗәгать итә. Хор шәһәр тормышының ыгы-зыгысын күрсәтү өчен дә хезмәт итә.

Спектакльнең сәхнә бизәлешендә келәм структура кора торган образ булып китә. Тормыш төеннәре мотивы - үтәли мотив. Тамашачыларга XIX гасыр татар байлары-фабрикантларының көнкүрешен күрсәтеп, сценарий авторы роман авторы һәм тикшерүче-шымчы артыннан чит кешеләр язмышларының төеннәрен дә чишә. Билгеле булганча, классик рәвештә йоннан тукылган келәмнең бер квадрат метрында 90-360 төен булырга мөмкин.

Түшәмнән дистәләрчә төсле йомгаклар асылынып тора. Ирексездән, әкиятләрдәге тылсымлы йомгак искә төшә: үзеннән-үзе тәгәри һәм сөйгән ярларын эзләп, юлга чыккан юлчыларга сөйгән ярлары яшерелгән явызлык патшалыгына юл күрсәтә. Кагыйдә буларак, әкият герое Кощейның да, Дию пәриенең дә патшалыгына юлны белми. Эпик геройга Убырлы карчык ярдәмгә килеп, аның кулына тылсымлы йомгакның җебен тоттыра.

Грекларның Минотавр турындагы мифларында да шундый ук символны очратырга мөмкин. Тезейны Ариаднаның юл күрсәтә торган җебе коткара. Андый җепләр һәрвакытта да күктән, югарыдагы башка дөньядан төшерелә. Йомгакка чорналган җеп югарыдан иңдерелә торган гыйлемнәрне символлаштыра. Ул әкият героен тиешле җиренә китереп җиткерә, иллюзияләреннән арындыра, ялгышларын күрсәтеп бирә. Төрле төстәге йомгакларны күргәч, хәтергә «Җепне җыйнасаң, йомгак булыр» дигән татар халык мәкале килә. Без Мусаның тормыш мәгънәсен табуына шаһит булабыз.

Спектакльдә йомгак күпкырлы итеп шәрехләнә. Бер яктан, ул һәрбер персонажның тормыш йомгагын символлаштыра, икенче яктан, геройлар тирәсендәге гайбәтләрдән арынып, тамашачыга кунакханәдә булган фаҗигадәге гаепле кешене ачыкларга ярдәм итә. Төрле төстәге җепләр төрле кешеләрнең язмыш җепләреннән чорналган язмыш йомгагы образына җыйнала.

Йомгаклар сәхнә пространствосының *өске ягын* формалаштырса, *аскы ягын* - “Казанский телеграф” газетасы төргәкләре оештыра. Режиссёр шул рәвешле вакыт рухын, татар сәүдәчелегенең яңа буынына үтеп кергән европалашу рухын ассызыклый.

Фотоаппаратка мөһим урын бирелә, аның сәхнәдә кат-кат күренүе персонажларның тормышындагы кискен үзгәрешләрне белдерә. Муса хөкем вакытында үзенә кемнең дус, кемнең дошман икәнлеген ачыклый. Әлеге күренешләрдә ут мөһим рольне уйный.

*Өйләнү турындагы сюжетта* туку станы образына шактый урын бирелә. Әлеге станда Зөләйханың тукып бетерелмәгән келәме кала. Финалда ул, намусын югалтудан куркып, үз-үзенә кул салырга мәҗбүр булган гашыйк кызны яклап кала алмаган якыннарына телсез шелтә булып аңлашыла. Келәмнең төп бизәге – *гомер агачы* – тукылып бетмичә калган. Биредә бизәкнең *гомер агачы* булуы да, аның тукылып бетмәве дә очраклы түгел. Зөләйханың, морадына ирешә алмыйча, гомере өзелүгә ишарә итә алар.

Мәхәббәт сюжетының үстерелешендә *туку станогы* импровизацияле арфа – саз ролен дә уйный, ул тамашачыларда күңел кыллары турында күзаллау тудыра. Мәхәббәт өчпочмагында катнашучы һәрбер персонаж икенче берәүнең күңел кылларында уйный, сөйгән кешесенең йөрәк түрендә урын алырга хыяллана. Геройларның хыялларында гыйшык объекты мифлаштырыла һәм хатын-кыз-сирена образына әверелә башлый.

Спектакльнең төп идеясе – җинаять барыбер үз җәзасын алачак. «Дошман – аяктан, дус баштан йөри» дигән татар халкы гыйбарәсе дә бар. Габденнасыйрның дус түгел икәнен Муса күрми, аңа эч серләрен сөйли. Хәтта өлкәннәр, күпне күргән туганнары, танышлары “ул – астыртын” дисәләр дә, ул соң чиккәчә моңа ышанмый. Ышанганда инде соң була... Дөрес, тәмам соң булып чыкмый, ул котылып кала ала әле» [17].

Р. Әюпов үз сценариенда персонажлар системасына зур игътибар биргән. Спектакльдә төп геройлар гына түгел, һәрбер эпизодик персонаж да тулысынча ачыла. Әсәрдә төп герой булмаган Зөләйха спектакльдә тулы канлы герой булып катнаша. Р. Латыйпов фикеренчә, Р. Әюпов спектаклендә «Зөләйха (Илсинә Миңнемуллина) образы аша башка идеяләр дә үтеп кергән. Зөләйханың өен ташлап китүе кызганыч та, гыйбрәтле дә. Гашыйк булдым дип, бөтен дөньясын ташлап чыгып китүчеләр бүгенге заманда да бар. Кыз үзенең беркатлылыгы, ахырын уйламыйча эш итүе белән кызганыч та... Егетне дә гаепләп булмый – ул кызның шул дәрәҗәдә үзенә гашыйк икәнен күзаллый алмаган, Зөләйхадан бернинди хәбәр-хәтер булмагач, үзенең тормышын аннан башка гына корырга булган... Кыз белән егетнең мәхәббәт тарихы, детектив әсәр кысаларыннан чыгып, мелодрамага хас булганча, бик матур итеп тәкъдим ителгән. Аны шушында матур итеп төгәлләп куясы, аларны бергә калдырасы килә башлый... Ләкин юк – кыз һәлак була, ә егеткә шушының белән яшисе... Әмма инде җинаятьтән котылып калган егет бу хакта уйламый да, аның алдында юллар ачыла, ул дошманнан котыла, чибәр, акчалы кызга өйләнә… Бу фикерләр, бу уйлар әле аңа соңыннан киләчәк» [17].

Р. Әюпов спектакленең үзенчәлеге шунда ки, режиссёр-сценарий авторы европалаштырылган сюжетны *шәрык әкияте* киемнәренә киендерә. Моңа беренчеләрдән булып журналист Р. Мөхәммәтова игътибар итте: «Европача “пешерелгән” әсәр “шәрыкчә” тартмага салынган. Бәлки, бу – мәхәббәтне Шәрык әкияте итеп күз алдына китерүдәндер» [18]. Шәрык биредә костюмнарда һәм музыкада чагылыш таба.

Рәссам Б. Гыйльванов мәхәббәтсез, исәп-хисапка корылган өйләнү темасын үстереп,

Хәдичәнең костюмын аерым игътибар белән эшли. Спектакльдә фәскә - чигеп һәм вак тәңкәләр белән бизәлгән төймә кебек бәләкәй кәләпүшкә мөһим урын бирелә. Әсәрнең исеменә үк чыгарылган акча, спектакль пространствосында тормыш деталеннән күпмәгънәле символга кадәр үстерелә. Төп персонажларның гамәлләре мотивларында акчаның роле Хәдичә костюмының үзенчәлекләре аша ассызыкланган. Р. Латыйпов төгәл билгеләгәнчә, «Хәдичәнең төп байлыгы – акчалары икәне аның "йөзенә язып куелган" дип әйтеп була. Аның битен алтын тәңкәләр каплап тора. Ул аларны бик сирәк кенә күтәрә – бу аңлашыла да, көрәш бит акча тирәсендә бара».

«Бөтен нәрсәне дә акча белән хәл итәләр монда. Дөреслек өчен тырышу да, "ялган җиңсен" дию дә – барысының да артында акча ята. Юк кына әйбер өчен дә бар да кулын сузып тора һәм, шул акча өчен, әллә нинди рәвешләргә керергә әзерләр. Кыен хәлгә калгач, берсе дә гаделлек эзләми, ә дөреслекне сатып алмакчылар. Алар әллә инде гаделлеккә бөтенләй кул селтәгән, әллә инде бу мөмкин хәл түгел – дөреслек турында монда авыз ачып сөйләүче дә юк», – дип нәтиҗә ясый Р. Латыйпов [17].

Режиссёр хронтопны оештырганда, аңа зур мәгънә сала. Спектакльгә динамиканы *ат арбасы* белән *вагон* образлары да бирә. Хатирәләр пространствосы, Мусаның сагышлары һәм аның адвокат белән эшлекле сөйләшүе стилистик яктан антитеза аша күрсәтелә. Асраулар (Эльвира Хәйретдинова – Азат Җиһаншин), шулай ук полицейский (Индира Гайфуллина) һәм шымчы дел-арте театры традицияләрендә бирелә.

Мәхәббәт сюжетын үстереп, спектакльнең авторлары игътибарларын мәхәббәт өчпочмакларына юнәлтә: *Зөләйха – Муса – Хәдичә, Муса – Хәдичә – Габденнасыйр*. Яучылык сюжеты костюмнар стилистикасы белән көчәйтелә. Зөләйханың кырымча бәйрәм костюмы алтын ука белән чигелгән. Героиняның социаль чыгышы шулай ассызыклана. Билгеле булганча, кырым татарларының туй киемнәрен тегү өчен, кыйммәтле тукымалар кулланыла: бәрхет, парча, ефәк. Кырым татарларының символик төсе - кызыл төс, шуңа да спектакльдәге хатын-кыз персонажлар кызыл яки алсу төстәге костюмнардан чыга.

Режиссёр спектакльдә яучылык темасын гротеск алымнары белән көчәйтә. Әлеге тенденция геройларның костюмнарында да чагыла. Кунакханә хезмәтчесенең костюмы инглизләр стилендә эшләнгән. Хезмәтченең образы "Уймак кыз" әкиятендәге Күсе образын хәтерләтә. Шул рәвешле *кәләш-товар* темасы тирәнәйтелә. Режиссёр буяуларны тагын да куерта: Хәдичәнең әтисе кызының теләкләренә колак салып та тормый. Аның бөтен уе, кызына отышлы кияү табып, байлыгын арттыру турында гына. Бу героиняның хәрәкәтләрендә дә ассызыклана. Хәдичә сөйгәне турында борчылганда, аның турында сөйләгәндә, йөзен ача, әтисен күргә йөзен тәңкәләрдән тукылган баш киеме белән каплый.

Спектакльдә мәхәббәт күренешләре юмор белән, урыны-урыны белән каһкаһәле итеп уйнала. Станок арфа-сазга әйләнә, аның кылларында уйнаганда, гашыйк парлар үзләренең хисләрендә эри. Бу вакытта пластика әһәмиятле роль уйный. Хореограф шәрык биюе эстетикасына мөрәҗәгать итә (пластика буенча режиссёр Марат Казыйханов). Романтик стилистикага видеографика да ярдәм итә (Максим Кунин). Анага язылган хат гашыйк Зөләйханың табигать кочагындагы видеосюжеты белән озатыла. Пейзаж манзаралары гашыйк булган кызның романтик табигатен күрсәтү өчен хезмәт итә. Татар халык җыры «Җиңгәче»не җырлап яучылау һәм кәләшне киендерү сәхнәсе дә лирик төсләр белән баетылган. Режиссёр антитеза алымын янә оста файдалана: героиняның сагышлары ("Ай җиңгәче, сөйгәнемне димләче") туганнарының киңәшләре белән каршылыкка керә. Кәләшнең сайлау мөмкинлеге булмау темасы татар сөлгесеннән божра ясау аша ассызыклана.

Детектив табышмагын чишүдә Зөләйханың әнисе мөһим роль уйный, ул кызының барысы да язылган хаты турында сөйләп, үз-үзенә кул салуы турындагы "сер төенен чишә".

Муса белән Габденнасыйрның көрәше спектакльдә Сабантуй батырлары мәйданындагы көрәш стилендә эшләнгән. Мусаны күтәреп, Габденнасыйрны фаш итәр өчен, режиссёр игътибарны аларның костюмнарына юнәлтә (Муса ак күлмәктән) һәм аларның йөзләрен икесен ике якка карата: идеаль герой яхшылыкка, начар герой явызлыкка таба йөз тота.

## Нәтиҗәләр

Р. Әюпов сценарийны эшләгәндә, мөмкин кадәр романга тугрылык сакларга омтыла. XIX гасыр ахырында З. Бигиев үзенең детектив романын язганда, беренче детективлар авторлары – француз язучыларына йөз тота. XXI гасырда роман буенча куелган «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» спектакле авторлары (режиссер-инсценировка ясаучы Р. Әюпов, рәссам Б. Гыйльванов, композитор Й. Бикчәнтәев, видеограф Максим Кунин) татар театры сәхнәсендә детектив сюжетны “миллиләштерү” эшендә кызыклы алымнар табарга омтылганнар. Сәхнә куелышында Казан, Петербург хронотоплары салмак кына Кырым (Шәрык) белән үрелеп китә. Яучылык сюжеты спектакльдәге хатын-кыз образларының костюмнарында (костюм детальләре, төсләр), биюләрдә үзе турында белдерә.

## Йомгаклау

«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» спектаклен (реж. Р. Әюпов), һичшиксез, Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрының иҗади уңышы дип бәяләргә була.

**Әдәбият**


1. Мустафин Р.А. Детективная литература // Татарская энциклопедия. Т.2. Казань: Институт татарской энциклопедии, 2005. С. 264–265.
2. Галиуллин Р.Р. Эволюция детектива в татарской литературе: автореферат дис. ... кандидата филологических наук : 10.01.02 / Казан. гос. ун-т им. В.И. Ульянова-Ленина. Казань, 2007. 23 с.
3. Хафизов С.Х. Татарская проза второй половины XIX века: к вопросу формирования и развития просветительского реализма: диссертация ... кандидата филологических наук: 10.01.03. Казань, 1973. 199 с.
4. Шаветт Э. Охота за миллионами. Санкт-Петербург: ред. журн. «Б-ка для чтения», 1877. 312 с.
5. Шкилева Л. Ф. Проблема театральной инсценировки русского классического романа на советской сцене: (МХАТ, 30-е годы): автореферат дис. на соискание ученой степени кандидата искусствоведения. 17.00.01 / Гос. ин-т театр. искусства им. А. В. Луначарского. Кафедра истории рус. дореволюц. и сов. театра. Москва: [б. и.], 1972. 22 с.
6. Скороход Н.С. Как инсценировать прозу: Проза на русской сцене: история, теория, практика. СПб.: «Петербургский театральный журнал», 2010. 344 с.
7. Фардеева Д.Р. Национальная проза на сцене татарского государственного академического театра имени Г. Камала. Казань: ИЯЛИ, 2014. 188 с.
8. Гайнуллин. М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX века / АН СССР. Казан. ин-т языка, литературы и истории. Казань: Таткнигоиздат, 1966. 435 с.
9. Мусин Ф. Заһир Бигиев // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 2 т.: XIX йөз татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр, 1985. Б. 302–318.
10. Бигиев З. Зур гөнаһлар: романнар, сәяхәтнамә. Казан: Татар. кит. нәшр. 1991. 382 б.
11. Миңнегулов Х. «Исмең синең милләт яшәдекчә яшәр» // Мирас. 1995. №11/12. Б. 97–103.
12. Бәширов Ф. Заһир Бигиев // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 3 т.: XIX йөз. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 392–400.
13. Ахунов А. Ачылмаган серләр // Идел. 2009. № 6. Б. 30–33.
14. Бигиев З. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (Р. Әюпов инсценировкасы) // Р. Әюпов шәхси архивы. Кулъязма. 04.08. 2022. 19 б.
15. Бигиев З. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» // https://minzalateatr.ru/tizd-n-premera-14-oktyabr-zakir-bigiev-lef-yaki-g-z-l-kyz-h-dich/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.12.2022).
16. Барт Р. S/Z / пер., ред. отв. Г. К. Косикова, пер. В. П. Мурат. Москва: РИК «Культура», 1994. 303 с.
17. Латыйпов Р. «Өлүф», яки Акча барына да хуҗа: Минзәлә театры беренче татар детективын сәхнәләштерде // URL: https://intertat.tatar/news/oluf-yaki-akca-baryna-da-xua-minzala-teatry-berence-tatar-detektivyn-saxnalasterde-5855439?ysclid=leb9qjdcu 8775400611
18. Мөхәммәтова Р. Минзәлә театрында премьера: «Өлүф...» яки Бигиевнең феноменальлеге нидә? // URL: https://intertat.tatar/news/minzala-teatrynda-premera-oluf-yaki-bigievnyn-fenomenallege-nida-5855778?ysclid=lebdmrgf6e70884822 (мөрәҗәгать итү вакыты: 02.11.2022).

# ДЕТЕКТИВ ЗАГИРА БИГИЕВА «ТЫСЯЧИ, ИЛИ КРАСАВИЦА ХАДИЧА» НА ТАТАРСКОЙ СЦЕНЕ

**Чулпан Афраимовна Зарипова-Четин**,
Кавказский университет,
Turkey, 36000, Kars/Center,
chulpancetin@gmail.com.

**Гульуся Габдрашитовна Аксой**,
Бартынский университет,
Турция, Бартын, Факультет Агаджи, 54,
gaksoy@bartin.edu.tr.

Статья посвящена изучению особенностей сценической интерпретации первого татарского детектива «Тысячи, или красавица Хадича» З. Бигиева режиссером Р. Аюповым. Систематизирован материал по степени изученности этого произведения в татарском литературоведении. Охарактеризована система персонажей в инсценировке, выявлен идейно-художественный потенциал образов. В статье раскрыты особенности переплетения восточных и западных традиций в сценической интерпретации прозы. Доказано, что Р. Аюпов прибегает в своем спектакле к синтезу разных видов искусств: литература, кино, танец, музыка, цирк.

**Ключевые слова**: татарская литература, татарский театр, детектив, Закир Бигиев, Ренат Аюпов